ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

25 06 2021 г. № 618

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге, тәртибе турында» 2017 елның 31 октябрендәге 672 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы «Аларны тиешенчә җыймау, тупламау, кулланмау, зарарсызландырмау, транспортламау һәм урнаштырмау гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зарар, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган яктырту җайланмалары, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында» карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны җыю һәм урнаштыру урыннары исемлеге, тәртибе турында» 2017 елның 31 октябрендәге 672 номерлы карарына (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Түбән Кама муниципаль районы территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны җыю урыннары исемлеген раслау турында»;

карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымта нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны җыю урыннары исемлеген расларга»;

карарның 2 пунктын төшереп калдырырга;

карарның 3, 4 пунктларын 2, 3 пунктлары дип санарга;

карарга 1 нче кушымта үз көчен югалткан дип танырга;

карарга 2 нче кушымтаның нумерацион башламында «2 нче кушымта» сүзләрен «кушымта» сүзләренә алмаштырырга.

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны матбугат басмасында һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г. Нигъмәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче А.Г.Сәйфетдинов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «25» 06
618 номерлы карарына
кушымта

Түбән Кама муниципаль районы территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны җыю урыннары исемлеге

1. Түбән Кама районы, Афанас авыл җирлеге, Олы Афанас авылы, Яшьләр ур., 15.

2. Түбән Кама районы, Ширәмәт авыл җирлеге, Ширәмәт авылы, Кооператив ур., 1 «А».

3. Түбән Кама районы, Сухрау авыл җирлеге, Сухрау авылы, Пролетар ур., 12 «Б»

4. Түбән Кама районы, Макаровка авыл җирлеге, Югары Уратма авылы, Яшьләр ур., 2.